ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2024 ел Баулы шәһәре № 156

2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, «Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына социаль ярдәм чаралары күрсәтү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2020 елның 21 июлендәге 48-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тулысынча туклану белән тәэмин итү, «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклануны оештыру турында» СанПин 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү максатларында сәламәт туклануны оештыру өлешендә, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның

үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 7 ноябрендәге
156 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

2025 елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативы

| Норматив атамасы | Уку чорында бер укучыга көнгә бәя нормативы, сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү бәясе нормативы | 9,6 | 10,0 | 10,4 |